СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**10 март 2026 ел** **№ 1**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 14 ноябреньдә 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Наласа авылында Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2026 елның 25 мартында 11 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Наласа авылында Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2026 елның 25 мартында 12 сәгать 30 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пункта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: М.Вахитов ур.,М.Җәлил ур.,Жинү урамнарында яшәүчеләр

2нче этап: Үзәк ур.,Яшьләр урамнарында яшәүчеләр

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 14 ноябреньдә 2 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авылы, Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Наласа авылында М. Вахитов һәм Яшьләр урамнары буенча су агызу торбаларын алыштыруга материаллар сатып алу, һәм урнаштыру);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу һәм урнаштыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Наласа авылында тимер-бетон боҗралар сатып алу (3 данә),эчке краннарын алыштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябреньдә 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Наласа авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы: И.Р. Шакирова